АЙЛЫК ИҖТИМАГЫЙ-ПЕДАГОГИК
ҺӘМ ФӘННИ-ӘДӘБИ ЖУРНАЛ

ОЕШТЫРУЧЫЛАР:
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ХӨКҮМӘТЕ,
МӘГАРИФ МИНИСТРЛЫГЫ,
РЕДАКЦИЯ КОЛЛЕКТИВЫ

# Мәгариф

ФЕВРАЛЬ Татар телендә 1913 елның мартыннан чыга № 2 (768)

## БУ САНДА

**АҢ-БЕЛЕМ ВӘ ЭШ-ГАМӘЛ**

ИСМӘГЫЙЛЕВА С., САБИРОВА Ф.
«...Изге йөрәк мең яшәр» ... 3
САДРИЕВ Ә.
Эзтабарлар атлый ил буйлап ... 7

**БАШЛАНГЫЧ КЛАСС**

МИЯССӘРОВА И.
Хәкимҗан Халиков иҗатында экологик тәрбия ... 12
Татар теленнән дидактик материаллар ... 15
ПРЯМИЧКИНА С.
Сынлы сәнгать дәресләре ... 16
СИБГАТУЛЛИНА Ф.
Әтиләр сүзе – күңелнең күзе ... 18

**ТУГАН ТЕЛ ҺӘМ ӘДӘБИЯТ**

ЯХИН А.
Әсәргә ничек анализ ясарга? ... 20
ХӘМИДУЛЛИН Л.
Матбагачы Рәмиевләр ... 24
ШАКИРОВА Г.
Т. Миңнуллинның «Бәхетле кияү» комедиясен өйрәнгәндә .. 26
ӘЛИМОВ Х.
Татарны дөньяга танытккан герой-шагыйрь ... 28
ХӘСӘНОВА Ф.
Ренат Харис иҗатын өйрәнү ... 29
КАШАПОВ М.
Мөнәсәбәтле сүзләрнең төзелешенә карата ... 31

**Рус мәктәпләрендәге татар балаларына**

ЗАКИРҖАНОВ Ә.
Яшьлеген сагынучы әдип ... 33

**Рус балаларына – татар теле**

САФИУЛЛИНА Ф.
IX сыйныфта татар теле ... 36
КУТУЕВА Р.
Нәтиҗәле алымнар кулланып ... 40

**РУССКОЕ СЛОВО**

ХАБИБУЛЛИНА Л., КИСЕЛЕВА О.
Проблемы изучения теоретико-литературных понятий ... 43
МИРОШНИЧЕНКО Л.
О работе над стилистикой текста ... 46
НАСТЯВИНА Г.
Развитие орфографической зоркости ... 50

**Иностранный язык.**

ГУБАЙДУЛЛИНА А.
О преподавании английского языка в национальной школе 51
НИГМАТУЛЛИНА Э.
Игры на уроках немецкого языка ... 52

# «... Изге йөрәк мең яшәр»

(ЯШЬ БУЫНГА МИЛЛИ ТӘРБИЯ БИРҮ МӘСЬӘЛӘЛӘРЕ)

**Сания ИСМӘГЫЙЛЕВА, профессор, Фәйрүзә САБИРОВА, доцент**

Гомуми белем бирү эчтәлеге минимумы уку-укыту процессында гомуми, мәҗбүри, милли һәм региональ компонентларның бердәмлегенә ирешергә тәкъдим итә. Бу — укучыларны тормышка һәрьяклап әзерләү, милләт зыялылары итеп үстерү өчен кирәк. Бүгенге яшүсмер үзен бер милләтнең, димәк, үзенең туган татар халкының вәкиле итеп хис итсен, халкының үткәнен, башка милләтләр белән аралашып-катнашып киту сәбәпләрен, ихтыяҗларын һәм мәнфәгатьләрен белеп үссен, катнаш гаиләләр барлыкка килүе милләтнең милләт булып саклануына тискәре йогынты ясавына төшенсен, милли, рухи хәзинәләребезне кадерләргә, сакларга һәм баетырга, алар белән горурланырга сәләтле, үз халкының һәм фәнни, һәм мәдәни, һәм хезмәт казанышларына теләсә кем алдында, теләсә нинди аудиториядә дәлилле, ышандыргыч бәя бирергә әзерлекле булсын.

Белем эчтәлеге минимумы нигезендә укыту, укучыларның базис программаларында күрсәтелгәннәрнең барысын да төпле, аңлы, иҗади үзләштерүенә ирешү — югарыда күрсәтелгән бурычларны үтәүдә төп шарт. Татарстанның төрле илләр белән элемтә урнаштыру шартларында Республикабызның дәүләтчелеген ныгыту, төбәкнең иминлеген һәм муллыгын кайгырту эшләрендә катнашу белән беррәттән, татар баласы һәр мәсьәлә турында дөрес фикер, эш йөртә белергә, милләтенең, туган төбәгенең, ниһаять, үзенең нәселенең асыл сыйфатларын киң пропагандалау күнекмәсенә ия булырга тиеш. Белем эчтәлеге минимумында, «Мәгариф турында» Татарстан Республикасы Законында, «Татар мәгарифен үстерү концепциясе»ндә, «Татарстан Республикасы гомуми белем учреждениесе турында типовой положение»дә һ. б. әнә шундый таләп куела.

Әйтергә кирәк; уку-укыту процессына болай якын килүнең бездә күркәм традициясе бар. XIX гасыр ахырларында, бигрәк тә XX йөз башларында мәктәп-мәдрәсәләрдә, дин өйрәнү белән беррәттән, шәкертләргә фәннәр дә укытылган. Иж-Буби авылындагы Буби мәдрәсәсендә, мәсәлән, 1908 елгы укыту планына төрки (татар) теле һәм әдәбияты, гомуми тарих һәм фәлсәфә тарихы, арифметика һәм хисап теориясе, геометрия, география, табигать белеме, рус теле, физика, химия, гыйльме сәрвәт (мал гыйлеме), астрономия, француз теле, бухгалтерия, мантыйк, методика һ. б. кертелгән. Фәннең теләсә кайсы тармагы турында сөйләүче дәреслекләр нәшер ителгән. Берничә вариантта булу сәбәпле, аларны альтернатив кулланырга мөмкин булган. Төрле кыйраәт (уку) китапларында әдәби әсәрләр һәм алардан өзекләр, төрле өлкәләр турында фәнни мәгълүматлар да урнаштырылган. В. В. Радловның «Белек» (Казан, 1872), С. Рахманколыйның «Монтазан кыйраәт китабы» (Казан, 1909), Ш. Ибраһимовның «Рәсемле фәнни кыйраәт» (Казан, 1912), Г. Бубиның «Кыйраәт төркия» (Казан, 1908), Х. Искәндәровның «Белек йорты» һ. б., һ. б. дәреслекләр — шуңа мисал. Ш. Ибраһимов, Г. Буби, Х. Искәндәров дәреслекләрендә аерым фәннәргә махсус бүлекләр багышлана. Физикага багышланган бүлекне, мәсәлән, Гобәйдулла Буби (Фәйзи) «Хикмәт табигыя» дип исемли, һәм анда механика, электр, оптикадан шактый катлаулы мәгълүматлар күңелле итеп, укучыларның тормышы, тәҗрибәсе, күзәтүләре нигезендә бәян ителә. Белемнең уку дәреслекләрендә әз-әзләп гади һәм аңлаешлы итеп бирелә баруы укучыларны фәннең үзен системалы өйрәнүгә җирлек әзерли, белемнәрне сынаптикшереп үзләштерүгә ярдәм итә торган шартларны булдыра. Аерым фәннәрдән басылып чыккан дәреслекләрнең эчтәлеге, төзелеше, методик лабораториясе бүгенге дәреслек төзүчеләр өчен кирәкле юнәлешләрне бирә алыр иде.

Татарча физика дәреслекләрен төзүдә, мәсәлән, Уфадагы «Госмания» мәдрәсәсе мөгаллиме Габдулла Шонаси зур тырышлык һәм осталык куя. Ул «Хикмәт табигыя» дәреслеген (Уфа, 1916) рус һәм француз авторларының, бигрәк тә К. Краевич һәм А. Гано хезмәтләре нигезендә яза. Ләкин турыдан-туры тәрҗемә итми, күбрәк үз тәҗрибәсенә таяна. Дәреслек тәҗрибәләрне аңларга ярдәм итә торган рәсемнәр белән бизәлгән, анда үзенчәлекле, татар тормышына, төбәккә бәйләнешле биремнәр һәм сораулар тәкъдим ителгән. Физика терминнары рус һәм татар телләрендә бирелгән. Габдулла Шонаси Октябрь инкыйлабыннан соң да физика дәреслекләре төзүдә актив катнаша. Башка фәннәрдән дә дәреслекләр үзләренең халыкчанлыгы, милли рухы, гыйльми төгәллеге белән аерылып торалар. Чорының күренекле кешеләре, зыялылары гыйлем эстәүне,

фәнни белемнәр үзләштерергә кирәклеген тәкрарлап торганнар, мөгаллим һәм шәкертләргә киңәшләрен биргәннәр. Күренекле мәгърифәтчебез Ризаэтдин Фәхретдиннең, мәсәлән, «Җәвамигуль калим шәрхе» дигән хезмәтендәге (Ырынбур, 1916) түбәндәге сүзләре генә дә ни тора: *«Кулыңнан килсә, форсат тисә, галим бул, бу эш насиб булмаса, шәкерди вә гыйлем эстәүче бул, бу да мөяссар булмаса, гыйлемне дуст күр... Гыйлемне дуст күрү исә аның әһлене хөрмәт итү, халык арасында аны тарату, белдерү һәм үгрәтү, укучыларга, һәм дә мәктәб вә мәдрәсәләргә, укытучыларга мадди вә мәгънәви ярдәмнәр бирүдән, мөҗәррәт зани яки искедән мирас булып калган көнчелекләр сәбәпле гыйлем әһелләренә дошманлык кылулар вә гайбәтләрне сөйләүләрдән, гыйлем-мәгърифәтне сүз тасаррыф итүдән саклану вә гомумән гыйлем юлында булган кешеләр белән яхшы мөгамәләдә булудан гыйбарәттер»* («Идел» журналы, 1990, № 12, 44 б.).

Коръәннең 700 ләп аяте гыйлем эстәргә, укымышлы булырга, китап сүзен изге санарга, белемле кешеләрне хөрмәт итәргә, үз белемеңне башкалар белән уртаклашырга өнди. Бу хакта халык мәкаль һәм әйтемнәре иксез-чиксез. Безнең татар халкы үзенең укымышлылыгы, белемгә омтылышы белән аерылып торган. Мәктәп, мәдрәсәләрдә гарәп, фарсы, төрек телләрен өйрәнү шәкертләргә Көнчыгыш илләренең уку йортларында табигый рәвештә укуларын дәвам итәргә мөмкинлек биргән. Г. Баруди, Ш. Мәрҗани, Р. Фәхретдин, Ф. Кәрими, З. Кәрими, М. Гафури, Ш. Камал һ. б. — шундыйлардан. Көнбатыш югары уку йортларында белем алган, хәтта укыткан шәхесләр дә бездә аз булмаган. Хатын-кызлардан, мәсәлән, Казан университетын тәмамлаган Гайшә Хәлфина, Женева университетында белем алган Суфия Сыртланова һ. б.

Белемгә, фәннәр өйрәнүгә хөрмәт белән карау елдан-ел ныгый бара. Балаларга белемне киң дөньяга чыгарлык итеп бирү — милли мәктәпнең гаять җаваплы, җитди һәм өметле бурычы. Укучыларны теге яки бу фән үсешенә сизелерлек өлеш керткән милли галимнәребез хезмәтләре, казанышлары белән таныштыру — әһәмиятле бурыч. Бу уңайдан түбәндәге галимнәребезне искә алып үтү урынлы булыр:

**химиклар:** Г. Камай, Ф. Фәйзуллин, Б. Хөснетдинов, Ю. Сәмитов, В. Мирзаянов;

**физиклар:** М. Зарипов, К. Вәлиев, А. Әминов, Ф. Әүхәдиев, Ә. Садыйков, Ә. Шәрифуллин, Т. Нәҗметдинов, Ш. Әхмәров, Р. Низамов, Ә. Әминова, Р. Сәгъдиев һ. б.;

**механика фәнен үстерүгә зур өлеш кертүчеләр:** М. Әминов, Р. Насыйров, З. Хәйруллин, М. Лотфуллин...;

**математиклар:** П. Назимов, Р. Билалов, А. Хатипов, Ш. Яфаров, Р. Бухараев, Г. Салехов, Н. Халитов, Р. Абайдуллин, Д. Мөштәри...

Татарстан Фәннәр академиясе ачылуга 5 ел тулуга багышланган академия җыелышына (1997) Америкадагы Мериленд университетыннан дөньяга мәшһүр профессор Рональд Сәгъдиев кайта. Россия Фәннәр академиясенең физика-технология институты директоры Камил Вәлиев, Япониядә эшләүче Кев Салихов, Татарстанның үзендә яшәп-эшләп дөньяга танылган галимнәр: Данияр Мөштәри (ихтималлылык тәгълиматы), Илдуз Закир (металлар, калай ябыштыру технологиясе), Фоат Гарифуллин (химик, нефть продукцияләре), Әбрар Кәримуллин, Мирфатыйх Зәкиев, Фоат Ганиев (милли тел, милләт тарихы, мәдәнияте өлкәсендә армый-талмый эшләүчеләр) катнаша.

Казан галиме Ким Шакиров Ньютон законына төзәтмәләр кертә.

Җыеп кына шуны әйтергә кирәк: уку материалларындагы, программа һәм дәреслекләрдәге француз, инглиз, немец, рус, еврей фамилияләре янына татар фамилияләрен дә куяр вакыт җитте хәзер. Бу яктан Алабуга районы Морт мәктәбе мөгаллимнәренең тәҗрибәсе игътибарга лаеклы. Монда мәктәпне тәмамлаган галимнәр белән очрашулар оештырыла, аларның ачышлары, темага туры китерелеп, җентекләп өйрәнелә. Мәктәпне тәмамлаган Т. Ә. Әхмәтов — танылган химик, академик. Р. Г. Хәйбрахманов — шулай ук академик, техник фәннәр докторы. Аның нефть продукцияләрен транспортлаштыру өлкәсендәге ачышлары укучыларга физиканың транспорт турындагы бүлеген өйрәнгәндә ирештерелә. Хәзер бу мәктәп мөгаллимнәренең предметара бәйләнеш принцибын ничек гамәлгә ашырулары белән танышып узыйк. Элегрәк бары тик фәннәр арасындагы охшашлык-бәйләнешләрне ачу күздә тотылса, хәзер исә ул милли-рухи мәгълүматларны да колачлап ала. Мисал өчен X сыйныфта әдәбияттан Гаяз Исхакыйның «Зөләйха» трагедиясен өйрәнгәндә гамәлгә ашырылырга мөмкин булган багланышларны — интеграцияне күзәтик.

**Тарих:** XVI, XVII, XVIII гасырларда, XIX гасырның 60 нчы елларында татарларны көчләп чукындыруга бәйле тарихи фактлар. (Гаяз Исхакый үз әсәрендә, чорны әйтмичә генә, «Вакыйга алтмышынчы елларда» дип кенә язып куя. Кайсы гасырның 60 нчы еллары икәнлеген ачыклау кирәк.)

**География:** чукынудан качып, туган-үскән йортын-җирен ташлап киткән татарларның яңа урыннарда әр-яңадан тормыш корып җибәргән төбәкләренең географик картасы, табигый шартлары, флорасы һәм фаунасы, файдалы казылмалары һ. б.

**Рус теле һәм әдәбияты:** рус әдәбиятында трагедия жанрында иҗат ителгән әсәрләр; миссионерлыкка бәйле әдәби әсәрләр; лексика: монах, икона, поп, становой, казамат, каналья.

**Сынлы сәнгать:** чукындыруны чагылдырган картиналар.

**Кино сәнгате:** «Взятие Казани» фильмында Ядгар ханны чукындыруны күрсәткән кадрлар.

**Музыка:** «Ашказар» җыры.

**Театр сәнгате:** Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры куйган «Зөләйха» спектакле.

Төгәл фәннәрдән дә мисал булсын. Мәсәлән, физика курсында «Каты җисемнәр» темасы бар. VII сыйныфта бу төшенчә — матдәнең өч төрле халәте системасында, өлкән сыйныфларда исә каты җисемнәр үз эчендәге төрләре белән бирелә. Татар халкы тормыш-көнкүрешендә, гомумән, аның яшәешендә үзенә бер үзенчәлекле мөһим урын алып торганга, мөгаллим, әйтик, каты

җисемнәр системасына кергән төсле металларга махсус дәрес багышларга ният итә, һәм дәресендә түбәндәге компонентларның гармоник үрелүенә ирешелә:

**химия:** коррозия, төсле металларның коррозиягә бирешмәү сәбәпләре, моның әһәмияте;

**тарих:** Кубрат хан хәзинәсе һәм аның тарихи чыганаклары (файдалану өчен материал — «Сөембикә» һәм «Мәгариф» журналларының 1997 елгы 12 нче саннары);

**рухи хәзинәләр:** халык һөнәре буларак көмешчелек (беләзек, йөзек, муен асмалары ясау осталыгы); татарларда җиз комган һәм аның тыйбби сыйфатлары;

**халык каһарманнары:** Уралда алтын прииска хуҗалары атаклы меценатлар Закир (шагыйрь Дәрдмәнд) һәм Шакир Рәмиевләр;

**узаман:** Казанда көмешчелек остаханәсе.

...Тормышыбызда кооперацияләр, ассоциацияләр, корпорацияләр, фирмалар һ. б. эшчәнлегенең колач җәюе, эшләмичә дә күп «акча табу» мөмкинлеге булу, иң ямьсезе — илдәге икътисадый тотрыксызлык, эшсезләр саны арту, эш хакының ышанычсыз матди чыганакка әверелүе укучыларда фәннәрне үзләштерүгә битарафлык кебек яман күренешне китереп чыгарды. Моңа игътибар итмәү — зур ялгышлык булыр иде.

Бу урында кайбер күренешләргә аңлатма биреп киту урынлы булыр. Дистәләрчә еллар буе команда-административ системасы хакимлек итү сәбәпле, совет икътисады үзенең табигый юлы белән үсеп китә алмады. Хәзер базар мөнәсәбәтләренә күчү чоры, ә күчешнең катлаулы, четерекле булуы, чиновникларның властька, байлыкка, рәхәт тормышка табынуы, җинаятьчеллеге, күрелгән чараларның еш кына кире нәтиҗә бирүе сәбәпле, җитештерү процессында һәм иҗтимагый мөнәсәбәтләрдә тотрыклылык җимерелде, инфляция, җинаятьчелек көчәйде. Ләкин бу — чирле икътисад тудырган вакытлыча күренеш. Ул узып китәр. Югары квалификацияле белгечләргә, әзерлекле кешеләргә мохтаҗлык зур булыр. Бу — икътисадның тайпылышсыз кануны. Укучыларга менә шуны төшендерү зарур. Бу — беренчедән.

Икенчедән, балаларны кешенең ашау да эчү, киенү дә йоклау өчен генә тумаганлыгына инандырырга кирәк. Матди байлыклардан башка, рухи кыйммәтләр, рухи хәзинәләр дә бар бит әле. Рухи яктан бай кешеләр үзләренең мәгънәсендә бәхетле сизәләр. Шуның өчен дә укучыларны милли мәдәният, милли сәнгать белән таныштыру, туган тел һәм әдәбиятны, рус теле һәм әдәбиятын, чит телне өйрәтү — мөһим бурыч.

Өченчедән, укыту процессын укучылар белемне үзләштерүләрен тоярлык — аларны тормышта кулланудан канәгатьләнү хисе кичерүләренә ирешерлек итеп оештырырга кирәк. Монда мөгаллимнең үз укучыларын яхшы белүе, һәркемне кызыксындырырлык «серле» биремнәр тәкъдим итә белүе шарт. Шул «серне» ачкач, укучыны сөенеч-шатлыклар биләп алырлык булсын. Әгәр бала үзе ачкан белемнәр белән горурланып, үзе башкарган эшләрнең сыйфаты өчен һич югы бер мәртәбә дулкынланып алса, бу инде фәнни белемнәр файдасына көчле этәргеч булачак. Соңгы елларда татар мәктәбенең халыкчанлыкка йөз тотуы куанычлы: укыту-тәрбияне балаларның үз ана телендә оештыруга омтылыш көчәйде, укучыларны үз халкын, аның мөстәкыйльлеген, бәйсезлеген хөрмәтләргә, милли азатлыгын сакларга өйрәтүгә игътибар ителә башлады. Халык педагогикасындагы уңай тәҗрибәне, укыту-тәрбия гамәлләрендәге халыкчанлык традицияләрен нәтиҗәле файдалану чаралары эзләнә.

Тик шуны истә тотарга кирәк: укыту-тәрбиядә халык педагогикасының кешеләрдә күпкырлы әхлакый сыйфатлар тәрбияләүне максат итеп куюын даими истә тоту мөһим. Андагы фикер кешенең рухи дөньясын баетуга юнәлтелгән. Туган тел, туган җир, туган халык, ата-ана, кардәш-ыру, күрше-күлән, сөйгән ярлар халык педагогикасында изгеләштерелгән, әдәп-инсафлык, аеклык, сабырлык, шәфкатьлелек, сафлык, пакьлек, эчкерсезлек, һөнәрләр белү күркәм сыйфатлардан санала, кешеләрнең үзара мөнәсәбәтләренә гаять катлаулы һәм гаҗәеп нәзберек-нечкә гамәл дип бәя бирелә, һәм моның шактый катгый кануннары мәкаль һәм әйтемнәр булып формалашкан. Нинди генә катлаулы шартларда бармасын, халыкның тормышкөнкүреше үзенең табигый кысаларында дәвам итә һәм милли традицияләр, милли мәдәният казанышлары, тәрбия тәҗрибәсе даими рәвештә буыннан-буынга күчеп тора. Болар — милли кыйммәтләр, һәм аларны шулай ук «милли хис», «милли үзаң», «милли холык», «милли психология» төшенчәләрен укучылар күңеленә сеңдереп тору фарыз.

Укучыларга милли тәрбия бирү турында сүз алып барганда дингә мөнәсәбәт мәсьәләсенә дә тукталмыйча булмый. Тормышыбызны үзгәртеп тору сәясәте гамәлгә ашырылу нәтиҗәсендә диннең дә халык һәм мәдәниятебез тарихындагы әһәмиятен барларга мөмкинлек туды, дини җәмгыятьләр оешты, дин сабагы алырга теләүчеләр саны ишәйде. Бу исә укыту-тәрбиянең эчтәлеген, төзелешен һәм технологиясен, программа һәм дәреслекләрне яңадан карап чыгуны һәм яңабаштан төзүне көн тәртибенә куйды. Әлеге саба җилләре иң беренче чиратта татар әдәбияты курсына тәэсир итте. 1992 елда басылып чыккан татар әдәбиятын укыту программасы IX сыйныф укучыларын Коръәннең төзелеше, әхлакый һәм рухи эчтәлеге, сәнгатьчә эшләнеше, татар әдәбияты үсешендә тоткан урыны һәм традицияләре белән таныштыруны максат итеп куя. «Диннәр тарихы» дигән факультатив курс, «Татарстан һәм татар халкы тарихы», «Кеше һәм җәмгыять» һ. б. курслар да Ислам диненә, Коръәнгә мөнәсәбәтле мәсьәләләрне читләтеп үтмәскә тырыша башладылар. Иҗтимагый фән мөгаллимнәре күбрәк фәлсәфи, тарихи мәгълүматлар белән эш-фикерләр йөртсәләр, әдәбият мөгаллимен, әлбәттә, Коръәннең сәнгатьчә эшләнеше: андагы рифмалар аһәңе, аятьләр, һәрберсенә тормыш тоткасы булырлык тирән мәгънә салынган искитмәле, йөрәкләрне телгәләп ала торган моң...

Класстан тыш вакытта, Коръәнгә багышлап, түбәндәге чараларны үткәрергә була.

**Диспут темалары.**

— Коръәннең барлыкка килүе очраклы күренешме, әллә закончалыкмы?

— Нинди шартлар һәм Коръәннең үз сый-

фатларыннан нәрсәләр Коръәнне изге, олуг, могҗизаи, иң популяр китап дәрәҗәсенә күтәргән?

— Коръәнне дуслык, иминлек, тынычлыкны ныгытырга өнди, бер-береңә хөрмәт күрсәтергә өйрәтә торган китап, диләр. Бүгенге көндә нәкъ менә Ислам дөньясында террорчылык, кан коюэ ешаеп китүгә нинди дә булса аңлатма бармы?

— Ислам — гарәп сүзе, буйсыну, үзеңне Аллага тапшыру, дигәнне аңлата. Шул ук вакытта Коръәндә шәхес иреге мәсьәләсе дә күтәрелә. Мисал өчен «Сыер» сүрәсеннән 186 нчы аятьне, «Хаҗ» сүрәсеннән 40 — 41 нче аятьләрне китерергә була. Мондый каршылыкны ничек аңлатырга була?

**Җомга укулары темалары:**

М. Гафуриның — «Сөембикә», М. Укмасыйның — «Коръән укысам» шигырьләрен, Г. Тукайның һәм башка әдипләрнең — дини мотивларга язган әсәрләрен, А. С. Пушкинның — Коръән циклыннан үрнәкләр, Л. Толстойның — Ислам дине әһелләренә язган хатларын, мөнәҗәтләр, хәдисләр уку.

Коръән һәм Коръән тәфсирләренең бишеге булган Мәккә, Мәдинә, Истанбул, Иерусалим шәһәрләренә, Казан мәчетләренә һ. б. изге урыннарга читтән торып сәяхәтләр, мәчеткә экскурсия, мәчет, сарайларның гүзәл архитектурасы, аларның стеналарындагы бизәкләр, мозаика үрнәкләре белән танышу.

Сүз дә юк, безнең мәктәп, гимназияләр, лицей һәм көллиятләр — дөньяви уку йортлары. Аларның максаты яшьләргә дини тәрбия бирү түгел, ә бәлки дөньяга дөрес фәнни караш тәрбияләү. Дөрес фәнни караш тарих, мәдәният казанышы булган Ислам диненә, мәдәниятебезгә зур йогынты ясаган Коръәнгә дөрес бәя бирүне күздә тота.

Моңа кадәр сүз ирешкән уңышлар, алда торган бурычлар һәм аларга ирешү юллары — «яхшыдан үрнәк ал» тирәсендәрәк булды. «Яхшыдан үрнәк ал...» дигән мәкальнең дәвамы да бар бит әле. «... Яманнан гыйбрәт ал», дип өсти аңа халкыбыз.

Күңелеңне хафага салырлык нинди кире сыйфатлар хас соң безнең халыкка?

Бу — таркаулык, бер-береңә аяк чалу, көнләшү, дорфалык, татар барда хәтәр барлык, ялагайлык, хөсетлек, башка кешегә яла яга-яга булса да өстен чыгарга омтылу, коллык... Күптәннән килгән, әйтергә кирәк, канга сеңгән һәм, кызганыч ки, буыннан-буынга күчә килгән сыйфатлар. Әйтелгәнгә дәлил итеп тарихчы Һади Атласиның «Сөен бикә» исемле хезмәтеннән кайбер юлларны китерик. Мәсәлән, Казанның Явыз Иван тарафыннан алынуында татарларны да гаепләп, автор болай ди: *«Русларның Казан өстенә килүләре Казан корткычларының чакыруы буенча булган икәнлеге Сафагәрәй ханга беленде.... Казан бәкләре арасында йорт өчен тырышканнары булдыгы кеби, йортны бетерергә көч куйганнары, ушандык халык арасында коткы салып, арадагы берлекне югалтырга сәбәп булганнары да бар иде» (10 б.). «Исмәгыйль мирза кебек дин, милләт дигән нәрсәләрне белмәгән һәм шуның илә бәрабәр бөтен эшләгән эшләре шуларның киресенә булган сатлык мирзалар булып торганда, Иванның эше үзе теләгәнчә барыі торачак иде. Чынлап та. шулай булды (16 б.)*

Заманалар кырыслана, берәүләі фәкыйрьләнә, икенчеләр байый. Шәфкатьсез лек. Ата-аналарны ташлау. Талау. Үтереш.. Яшьләребезне ямьсез холыкларыбыздаі арындыру хәстәрен күрү бик кирәк. Балалар заман таләбенчә, өлкәннәрне һәрьяклап ку андыра торган шәхесләр булып үссен иде *Татар баласы ата-ана варисы гына түгел, ул* – милләт токымы, милләтнең киләчәге. Аныі рухи гарип булып үсүе татар халкының төбе тамырына үткен балта белән чабу дигән сүз Шулай итеп, укучы яшьләргә милли тәрби: бирү — гаять катлаулы, төрле яклы, иҗади һәм төптән уйланып эш итүне таләп итә торгаі изге гамәл! ~~Ул түбәндәгеләрне үз эченә~~ ала:

**1. Укыту-тәрбияне, белемнең дөньякүләм стандартларына нигезләнеп, туган телд: алып бару, башка телләрне туган тел ниге зендә өйрәнүне оештыру.**

**2. Укыту-тәрбиядә халыкның милли тра дицияләрен, педагогик тәҗрибәсен, этно *психологик үзенчәлекләрен, табигать түрын*дагы белем-тәҗрибәләрен кулланып, укучыларда интеллектуаль сәләт, югары әхлак сыйфатлары тәрбияләү.**

**3. Дәресләрдә һәм класстан тыш эшләрдә балаларны татар галимнәренең теге яки бу фәнне үстерүгә керткән өлеше, ачышлары, казанышлары, аларның халык хуҗалыгында тоткан урыны һәм дөньякүләм әһәмияте белән таныштыру. Әдипләр, артистлар, композиторлар белән очрашулар үткәрү, аларга багышлап кичәләр оештыру, стендлар һәм күргәзмәләр, альбомнар җиһазлау, туган төбәк әдипләре, галимнәренең тормышын, иҗатын өйрәнү.**

**4. Укытыла торган фәннәр арасында максатчан бәйләнеш булдырып, шулай ук милли рухи мирас һәм традицияләргә нигезләнеп, укучыларга белем-тәгълиматны гомумкешелек мәдәнияте һәм акыл эшчәнлеге нигезләре буларак тәкъдим итеп, балаларның милләт зыялылары булып үсүенә ирешү.**

**5. Укучыларның милли мәдәниятне, татар халкының рухи байлыгын үзләштерүенә, аның казанышлары белән горурлана белүенә ирешү, башка халыкларның да мәдәнияте белән кызыксыну, аны хөрмәт итү хисе тәрбияләү.**

**6. Татар халкының хуҗалык итү ысулларын, хезмәт традицияләрен өйрәнеп, яңа икътисадый мөнәсәбәтләр шартларында яшь буынны хезмәткә, тормыш итәргә әзерләү.**

**7. Туган як, туган йорт, туган туфракка ихтирам тәрбияләү максатында укучыларны җирле шартларны, туган як тарихын өйрәнүгә тарту, аларның милләтпәрвәр булып үсүенә шартлар тудыру.**

Халкыбыз тарихы, әдәбияты, мәдәнияте, гореф-гадәтләре, традицияләре белән таныштыру, аларны өйрәтү югары әхлакый сыйфатларга ия булган шәхес тәрбияләргә ярдәм итә. Шуңа милли тәрбия бирү мәсьәләләре һәрвакыт игътибар үзәгендә булырга тиеш.

Каты йөрәк бер яшәсә, изге йөрәк мең яшәр, ди халкыбыз. Бу сүзләргә тирән мәгънә салынган. Моннан аңлашылганча, кеше әхлаклы булса гына кешеләргә изгелек эшли ала.